ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районының**
**Келәнче авыл җирлеге Башкарма комитеты житәкчесе**
Кама Тамагы районы,
Келәнче авылы
тел. 8-(84377)- 33-4-31

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Руководитель Исполнительного комитета Клянчеевского сельского поселения**
Камско-Устьинский район,
с. Клянчеево
тел. 8-(84377)- 33-4-31

# КАРАР

2020 елның 30 гыйнварындагы 4 номерлы

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон,Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлегендә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 6124,86 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Келәнче авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең

гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2019 елның 14 мартындагы 9 номерлы карары көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Келәнче ав., Тукай урамы, 35 йорт;

- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Бәки ав., Фрунзе урамы 2 йорт ,

шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга .

4. Әлеге карар 2020 елның 1 февраленнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Д.А. Кадыйров

Кама Тамагы
муниципаль районы Келәнче авыл
җирлеге Башкарма комитетының
2020 елның 30 гыйнварындагы
4 номерлы карарына
1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлегендә җирләү буенча, гарантияле исемлек нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *( сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3670,18 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 522,27 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1932,41 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Кама Тамагы
муниципаль районы Келәнче авыл
җирлеге Башкарма комитетының
2020 елның 30 гыйнварындагы
4 номерлы карарына
2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Келәнче авыл җирлегендә җирләү буенча , гарантияле исемлек нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәяләре

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сумнарда)*** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне кәфенләү | 188,35 |
| 3. Җирләү өчен табут һәм башка кирәкле предметларны бирү һәм китерү | 3481,83 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (гәүдә калдыкларын) зиратка илтү | 522,27 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1932,41 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |